КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 май г.Казань № 366

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларын 65 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәгән затларга медик-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларын 65 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәгән затларга медик-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче; 2021 ел, 11 февраль, 70 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларын 65 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәгән затларга медик-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен хосусый медицина оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү кагыйдәләре.»;

2 пунктта «конкурс нигезендә сайлап алу» сүзләрен «сайлап алу» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларын 65 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәгән затларга медик-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын тормышка ашыру кагыйдәләренең 2 пунктында «конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче» сүзләрен «сайлап алуда җиңүче» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларын 65 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәгән затларга медик-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренең 6 пунктында «конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче» сүзләрен «сайлап алуда җиңүче» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларын 65 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәгән затларга медик-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектында катнашу өчен конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче хосусый медицина оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү кагыйдәләрен бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин